Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Күки авылы 2021 елның 16 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 10 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 12 номерлы, 2015 елның 29 маендагы 11 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 12 номерлы, 2019 елның 13 июнедәге 8 номерлы, 2020 елның 4 февралендәге 1 номерлы, 2021 елның 8 декабрендәге 3 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункттагы «беренче квартал беткәннән соң 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал – 15 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал - 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә» сүзләрен алып ташларга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 нче йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов